Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

11 ноябрь, 2019 ел № 2

## Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Надеждино авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыеннарын билгеләргә:

1.1. Аркатау авылында. 2019 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта 1 Май урамындагы чиркәү янында гражданнар җыенын үткәрергә:

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Надеждино авыл җирлеге Аркатау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, 2 төркем эшләмәүче инвалидларны, Чернобыль АЭСы калдыкларын бетерүдә катнашучыларны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Урта Ия авылында. 2019 елның 30 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Комаров урамы буенча 13 номерлы йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Надеждино авыл җирлеге Урта Ия торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, 2 төркем эшләмәүче инвалидларны, Чернобыль АЭСы калдыкларын бетерүдә катнашучыларны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.3. Надеждино авылында. Халык җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2019 елның 6 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Мәктәп урамы, 3 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Мәктәп, Яңа урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2019 елның 7 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Мәктәп урамы, 3 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Космонавтлар, Яшьләр урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Надеждино авыл җирлеге Надеждино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, эшләмәүче 2 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларны, биш һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге башлыгы И.З. Галәветдинов